| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

2019 елның 23 октябре № 38/5

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Контроль-хисап палатасы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 2011 елның 7 февралендәге 6-ФЗ номерлы Федераль законы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, Чүпрәле районы прокурорының 2019 елның 20 августындагы № 02-08-02-2019 протестын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 29 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2011 елның 9 сентябрендәге 11/5 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Контроль-хисап палатасы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1)** «Контроль-хисап палатасы рәисе һәм аудиторы вазыйфасына кандидатураларга карата таләпләр» **6 статьяның 2 пунктына** түбәндәге эчтәлекле 5 нче пунктча өстәргә:

«5) әлеге статьяның 3 пунктында каралган нигезләрнең булу-булмавы»;

**2) 11 статьяны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11 Статья. Контроль-хисап палатасы эшчәнлеген планлаштыру

1. Контроль-хисап палатасы, Контроль-хисап палатасы вәкаләтләрен исәпкә алып, җирле бюджет үтәлешен һәрьяклы системалы контрольдә тотуны тәэмин итү зарурлыгыннан чыгып, формалаша торган еллык план нигезендә үз эшен төзи. План мөстәкыйль рәвештә эшләнә һәм раслана.

2. Контроль-хисап палатасы эшчәнлеген планлаштыру контроль һәм эксперт-аналитик чаралар нәтиҗәләрен исәпкә алып, шулай ук Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы йөкләмәләре, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы башлыгы тәкъдимнәре һәм запрослары нигезендә гамәлгә ашырыла.

3. Контроль-хисап палатасының еллык эш планы планлаштырылган елның 30 декабренә кадәр раслана.

4. Контроль-хисап палатасының эш планына Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы йөкләмәләре, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгының планлаштырылган елның 15 декабренә кадәр Контроль-хисап палатасына җибәрелгән тәкъдимнәре һәм запрослары мәҗбүри кертелергә тиеш.

5. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы күрсәтмәләре, эш планын үзгәртү буенча Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгының тәкъдимнәре һәм запрослары Контроль-хисап палатасы тарафыннан алынганнан соң 5 эш көне эчендә карала.

6. Еллык эш планына үзгәрешләр Контроль-хисап палатасы Рәисе күрсәтмәсе белән раслана.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

3. Әлеге карар кабул ителгән көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы башлыгы, Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе М.Р. Гафаров